Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең
“Катнаш төрдәге 16 нчы “Сказка” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем
бирү муниципаль бюджет учреждениесе

КАБУЛ ИТЕЛДЕ
Азнакай шәһәренең
№16 “Сказка” балалар бакчасы
педагогик киңәшмәсендә
Протокол №1 25.08.2023 ел

РАСЛАНДЫ
Азнакай шәһәренең
№16 “Сказка” балалар бакчасы
мөдире
_______________ Л.С. Шигапова
Боерык №11 25.09.2023 ел

# “Тылсым илендә”

5-6 яшьлек балалар өчен
өстәмә белем бирү программа

Программаны төзеде:
1 квалификацион категорияле
тәрбияче
Зәкиева Г.М

Азнакай шәһәре, 2023 ел

**Эчтәлек**

Кереш өлеш 3-7 бит

Аңлатма язуы ........................................................................................... 7

Программаның максаты һәм бурычлары ........................................................ 8

Программаның актуальлеге ......................................................................... 8

Көтелгән нәтиҗә ...................................................................................... 10

Программаның билгеләнеше ....................................................................... 11

Эчтәлекне тәэмин итү принцибы ................................................................. 12

Күрсәтмәлелек чаралары ............................................................................. 13

Программаның эшләү этаплары ................................................................... 13

Программада эшләү төрләре ....................................................................... 13

Программаның тематик планы ..................................................................... 14

Программаның комплекслы-тематик планы ................................................... 17

Мониторинг ............................................................................................... 29

Кулланылган әдәбият .................................................................................. 31

## Кереш өлеш

**Чал гасырлар аралыгында**
**Йолдыз булып янасы бар!**
**Юл бирегез нарасыйга-**
**Анын ерак барасы бар,**
**Үзенә юл ярасы бар!**

**Р.Әхмәтҗанов.**

Безнең балачак инде күптән артта калды.Шулай да балачак безне һәрвакыт озата бара,безнең белән янәшә атлый.Балачакны гел кайтарасы килә,аның матур мизгелләре гел искә төшеп тора.Без әле дә күп әйберләргә балачак күзлегеннән карыйбыз,балачак тавышы белән сөйлибез.Ничек кенә шул балачакка кайтып килергә...

Балачак кеше тормышының уеннарга иң бай чоры.Әйдәгез,бергәләшеп театр уйныйбыз.Театр-балалар өчен сәнгатьнең иң аңлаешлы бер төре. Театральләштерелгән уеннар балачак дөньясына юл ача.Театральләштергән уеннарны балалар бик яраталар,чынбарлык итеп кабул итәләр,һәрбер бала үз ролен уйнарга тели.Моңа ничек ирешергә? Театр нәниләрнең иҗади һәм рухи потенциалларын ачарга,социаль тирәлеккә яраклашырга ярдәм итә.Алар үзләрен иреклe,табигый тоталар,иркен хис итәләр,сәләтләре ачыла.Уеннар аша сабыйлар шәхес буларак җәмгыятьтә үз урыннарын табарга өйрәнәләр, әйләнә-тирә белән танышалар,әхлак нормаларын үтәгәндә мөстәкыйльлек күрсәтәләр,дөрес фикерлиләр,иҗади сәләтләре ачыла.

Театральләштерелгән уеннар күп кенә актуаль педагогик һәм психологик проблемаларны чишәргә ярдәм итәләр,бигрәк тә:

-шәхеснең коммуникатив яктан үсүен тәэмин итү;

-әхлак тәрбиясе бирү;

-эстетик зәвык формалаштыру;

-сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү;

-конфликтлы очракларны чишәргә күнектерү,уңай эмоциональ халәт тудыру;

-хәтерне үстерү,ихтыяр көче тәрбияләү.

Балаларда милли үзаң тәрбияләү-мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү учрежденияләренең төп бурычларының берсе.Балаларны татар телендә дөрес һәм матур итеп сөйләшергә өйрәтүдә,аларны сәнгатьле сөйләм күнекмәсе булдыруда сюжетлы-рольле уеннар,сәхнә эшчәнлеге оештыру да аеруча нәтиҗәле.

Балаларның бөтен тормышы уенга бай.Һәр бала үз ролен уйнарга тели.Әмма моны ничек эшләргә? Баланы уйнарга,рольне үз өстенә алырга өйрәтергәме? Ә моңа,һичшиксез, театр ярдәм итәчәк.

Театральләштерелгән эшчәнлек күп кенә педагогик бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә,бигрәк тә сөйләм,интеллектуаль һәм сәнгать-эстетик үсеш

өчен,һәм шулай ук балаларны тәрбияләү,баланы рухи кыйммәтләргә тарту чарасы.

Театральләштерелгән эшчәнлек-мәктәпкәчә яшьтәге балаларда эмпатия үсешенең мөһим чарасы,ягъни кешенең мимика,интонация,ишарәләр буенча эмоциональ халәтен тану сәләте.

Уеннар рәвешендә тәкъдим ителгән халык иҗаты җылылык,игелек атмосферасын тудыра,сабыйларның әйләнә-тирәгә карата эмоциональ уңай мөнәсәбәтен формалаштыруга һәм аларның танып белү үсешенә ярдәм итә. Театральләштерелгән эшчәнлек сюжет-рольле уен белән тыгыз бәйләнгән,шуңа күрә уеннарның күбесе балаларның көндәлек мәнфәгатьләрен чагылдыра.Таныш шигырьләр һәм җырлар нәниләр өчен материал булып тора.Балаларның эчке киеренкелеген бетерү максатында кечкенә этюдлар үткәрү файдалы,аларда эмоциональ халәт балаларга сүз һәм музыка җайланмалары ярдәмендә тапшырыла.

Педагогик җитәкчелекнең мөһим максаты-баланың хыялын,аның иҗади сәләтен уяту.

Сәхнәләштерелгән күренешләрдә үзенең сәләт-мөмкинлеген сынап карау балага чиксез шатлык китерә.Мәктәпкәчә яшьтәге балалар бигрәк тә тәэсирләнүчән була.Алар экиятләрне сәхнәләштергәндә уңай персонажларга теләктәшлек итә,аларныңхәленә керә.Бу яшьтә балаларның күзаллау һәм уйлап табу сәләте көчле,алар фантазиягә бай.Шуңа күрә дә балалар үзләре уйнаган экиятнең төп идеясен яхшырак аңлый.Сәхнәләштерү аша балалар үзләренең сәләтләрен күрсәтә алалар.

Сөйләм телен үстерүдә экиятләрнең роле зур.Театр балаларны сихри дөньяга алып керә,аларның иҗади фикерләү сәләтен ачарга ярдәм итә,сөйләм телен үстерә,эстетик һәм әхлакый тәрбия бирә. Сәхнәләштергәндә балаларның сүз байлыгы арта,аваз культурасы,интонацияле сөйләве тәрбияләнә.Рольне уйный-уйный,бала экият дөньясына кереп китә,татар телен истә калдыру җиңеләя.

Урта төркемдә балаларны театральләштерелгән эшчәнлек белән таныштыру бурычы катлаулана.Алар экиятләрдәге хәлгә үз мөнәсәбәтен төгәлрәк белдерергә өйрәнәләр.Балаларда персонажларның щхлакый сыйфатлары турында күзаллау үсеш ала.Бу яшьтә сүзләрне дөрес әйтүгә,тәкъдимнәр төзүгә бирергә кирәк.Балалар сөйләме өстендә эшләү өчен әйтенүләр,мәзәкләр,такмазалар,артикуляцион күнегүләр кулланыла.

Сәнгатьле сөйләмгә гадәт баланы аудитория алдында чыгыш ясауга җәлеп итү юлы белән генә тәрбияләүгә мөмкин.Театраль яктан –балаларның уен тәҗрибәсе киңәя.Алар хәрәкәт ролендә һәм текстны яраштыра башлыйлар,пантомимика кулланалар.Методлар һәм алымнар катлаулана.

Балалар кирәкле атрибутларны мөстәкыйль сайларга,материалларны һәм костюмнарның элементларын вариатив файдаланырга сәләтле,кирәкле атрибутлар әзерләү процессына кертелә.

Өлкән төркемдә образлы башкару күнекмәләре камилләштерелә, башкарыла торган рольгә аңлы һәм җаваплы карый башлыйлар.Бала мини-спектакльләр куярга сәләтле була башлый.Баланы үз тәненә ия булырга

өйрәтү,хәрәкәт пластикасын үстерү,үз гамәлләрен башка герой белән килештерү бурычы куела.Сәнгатьлелек (интонация,мимика,пантомима) элементларына өйрәтүгә зур игътибар бирелә.Чыгышлардан соң балаларның артистлык сәләтләре яхшыра.Балаларга театральләштерелгән эшчәнлектә диалогларга бай сценарийлар куллананыла.Театральләштерелгән эшчәнлектә экиятләр,сәхнә күренешләре уйнала,иллюстрацияләр буенча рольле диалоглар,мөстәкыйль импровизацияләр,драматизация,башкару сәнгатьлелеген формалаштыру буенча күнегүләр,балаларның социаль-эмоциональ үсеше буенча күнегүләр үткәрелә.

Театральләштерелгән эшчәнлекне файдаланып,үзара бәйле мәсьәләләр комплексын хәл итәргә мөмкин:

-танып белү үсеше-чынбарлык турында төрле яклы күзаллауларны үстерү (театрның төрле төрләре;кешеләр һөнәрләре,театр уйлап чыгаручылар;табигать күренешләрен,хайваннарның һәм кошларның үз-үзләрен тотышын күзәтү);

-социаль үсеш-уртак эшчәнлек барышында балалар арасында уңай мөнәсәбәтләр формалаштыру;баланың үзенә карата хөрмәтен тәрбияләү; хис-кичерешләрне үстерү;аралашуның этик кыйммәтле ысулларын тәрбияләү;

-сөйләм үсеше –монологик һәм диалогик сөйләмне үстерүгә ярдәм итү;сүзлекне образлы аңлатмалар,чагыштырулар,синонимнар,антонимнар, эпитетлар белән баету;аралашуның тәэсирле чараларына ия булу;

-эстетик үсеш-әдәбиятка тартылу,хыял үсеше,сәнгать образын булдыру,сурәтләү алымнарының мөстәкыйль табылуына өйрәтү;

-хәрәкәтләрне үстерү-гамәлләрне һәм сөйләмне килештерү,иҗади хәрәкәттә кәефне чагылдыра белү,образның үсеш характеры һәм процессы, башкаруның сәнгатьлелеге.

Театр эшчәнлеген оештырганда түбәндәге принциплар исәпкә алынырга тиеш:

-эш тематикасының һәм ысулларының төрлелеге;

-педагогик процессны оештыруның барлык рәвешләренә театральләштерелгән уеннарны көн саен кертү;

-балаларның максималь активлыгы;

-ата-аналар белән хезмәттәшлек итү;

-төрле вариацияләрдә хәрәкәтләрнең,сөйләмнең,мимиканың, пантомимикларның ярашуын исәпкә алып,сайлап алу һәм күнегүләр.

Театральләштерелгән уеннар эчтәлеге буенча төрлечә булырга,әйләнә-тирә чынбарлык турында мәгълүмат алып барырга тиеш,шуңа күрә сюжетлар төзелә торган сәнгать әсәрен җентекләп уйларга һәм сайлап алырга кирәк. Балалар бакчасында тәрбия эше эчтәлеген яңарта бару, инновацион технологияләрне куллану — тормыш таләбе. Бүген тәрбия эчтәлеге күпкырлы һәм ул үзенә түбәндәге өстенлекле юнәлешләрне берләштерә: балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеген саклау, ныгыту, интеллектуаль тәрбия бирү һәм үстерү, шәхестә культуралылык сыйфатлары һәм рухи кыйммәтләр булдыру; гражданлык тәрбиясе һәм патриотик тәрбия бирү, төрле җенестәге балаларның үзара дустанә мөнәсәбәте һ.б.

Баланы төрле яклап үстерү өчен, иң беренче чиратта, аның нәрсәгә сәләтле булуын ачыклау да җитә. Бу очракта күпләгән санда түгәрәкләргә йөртүдән тыш, аңа туры килә торган берсен сайлап алырга мөмкин. Бакчадагы гомуми шөгыльләрдә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә- юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә- юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында театр куюю бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла.

Театрда балалар бик теләп катнашалар,бигрәк тә рус балалары бик теләп катнаша. Махсус театральләштерелгән тамашалар балаларның сөйләмен үстерүдә мөһим чара.

Балалар бакчасында театр балаларны тормышта һәм кешеләрдә гүзәллекне күрергә өйрәтә,гүзәл һәм игелекле тормыш алып баруга омтылу тудыра.Театрга мәхәббәт балаларда балачак хатирәләре генә түгел,ә балалар бакчасында яшьтәшләре,ата-аналары һәм тәрбиячеләре белән бергә уздырылган бәйрәм истәлеге дә булып кала.

Әгәр дә мин балада театраль уеннарга кызыксыну уятканмын, ә сабый уйнарга теләк белдергән,миңа ышаныч күрсәткән икән-димәк хыялланырга,
иҗат итәргә мөмкин!

## Аңлатма язуы

Эстетик –сәнгать юнәлешенең театр түгәрәге прграммасында балалар бакчасында 5-6 яшьлек балалар белән театраль түгәрәк эшчәнлеге алып бару өчен төзелгән программа :аңлатма язуы,еллык тематик план,еллык комплекслы-тематик план,методик тәкъдимнәр һәм түгәрәк эшчәнлегенең эшкәртмәләре бирелә.Бу программа туган телебезгә хөрмәт,театр сәнгатенә кызыксыну,сәхнәдә чыгыш ясап карау теләге уяту,татар халык авыз иҗатына һәм матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү максатын куя.

Программа үстерешле белем бирү һәм дидактик принципларга нигезләнеп язылды.Балаларның яшь үзенчәлекләре,индивидуаль сәләтләре,биремне башкару өчен көче җитү мөмкинлекләреисәпкә алынды.

Баланың мәктәпкәчә яшьтәге чоры-тирә-юньне йотлыгып өйрәнү,күп кичерешләрне үзенә туплау,кеше шәхесе формалашуда иң мөһим чор.Соңгы елларда тормышыбызда,яшәешебездә бара торган үзгәрешләрнең берсе-туган телгә,халыкның милли мәдәниятенә,рухи дөньясына игътибары көчәю.Бу исә бала туган көненнән башлап ана телендә тәрбия бирә башлауны,балалар бакчаларында максатлы рәвештә сабыйларны үз туган теленә өйрәтүнең иң актуаль мәсьәләләр рәтенә куйды.Ана теле-тою,сизү,йөрәк теле,рухи тамыр.
Рухи тамырдан акыл,фикер эшчәнлегенә,белем һәм күнекмәләр туплауга,кешеләрне,дөньяны танып белүгә юл кыскарак.Театраль уеннар барышында баланың характеры формалаша,логик фикерләве,танып-белү эшчәнлеге арта.Аларның күзәтүчәнлеге һәм кызыксынучанлыгы күзаллау үсеше белән бәйле.Бала фикер йөртә,бәхәсләшә,исбатлый,җавап бирергә өйрәнә.

Программа балаларның эстетик сиземләү,сәнгатьле сөйләм,иҗади сәләтләрен үстерүне күздә тота.Мөһим бурычлар-балаларның башкару осталыкларын үстерүне дәвам иттерү,үз теләкләре белән мөстәкыйль рәвештә хикәя,яттан шигырь сөйләү,аларны үзләре уйлап чыгару,алган тәэсирләре белән уртаклашырга,җырлы-биюле уеннар уйнарга омтылышларын үстерү,матур әдәбият әсәрләренең төрле жанрлары белән танышу,аларны аера белү,геройларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә белергә өйрәтү.Бу максатларда төрле курчак,кулдан ясалган уенчык, атрибутлар,костюмнардан,декорацияләрдән файдалану яхшы нәтиҗә бирә.

Театр эшчәнлеге уңышлы һәм нәтиҗәле узсын өчен:

-тиешле педагогик шартлар тудыру;
-өйрәтү эшчәнлеген яңарту;
-нәтиҗәле алымнардан файдалану;
-түгәрәк эшчәнлеген максатка ярашлы рәвештә алыштырып тору;
-педагогның балаларны яратып,күңел биреп,иҗади эшләве кирәк.

Тәкъдим ителгән материал балаларны олы,катлаулы,гаять кызыклы театр дөньясына алып керүдә һәм театраль белем серләренәөйрәтүдә файдалы ярдәмлек булыр дип ышанам.

**Программаның максаты:**

Театральләштерү алымнарын кертү аша балаларда театр сәнгатенә кызыксыну һәм омтылыш,зур сәхнәдә чыгыш ясап үзеңне сынап карау теләге уяту;балалар әдәбиятының иң матур үрнәкләре,татар халык авыз иҗатының төрле формалары белән таныштыру аша әдәби телдә сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү,эстетик зәвыкларын,иҗади сәләтләрен,башкару осталыкларын үстерү;халкыбызның әдәбияты.сәнгате,мәдәнияты,гореф-гадәтләре үрнәгендә әхлаклы ,югары культуралы шәхесләр тәрбияләү;

информация киңлегендә ориентлаша, мөстәкыйль рәвештә яхшы юнәлешне сайлый, чишелеш кабул итә белә торган бала тәрбияләү,сәхнәләштерү аша балаларның сөйләм телен үстерү.

**Бурычлар:**

-Балаларга театр турында белем бирү, театрның төрләре белән таныштыру;

-Сәнгать әсәрләре аша балаларның эстетик зәвыгын үстерү, сөйләм телен баету, аралашу культурасы тәрбияләү;

- Әкият геройларының хис – тойгыларын, халәт – кичерешләрен дөрес тасвирлый белергә өйрәтү;

-Театр сәнгатенә карата мәхәббәт, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту;

- Әкиятләр белән кызыксынуларын үстерү, коллектив эшендә катнашу теләге тәрбияләү;

-Матурлыкка омтылыш, сәнгать кешеләренә хөрмәт тәрбияләү;

-Төрле театральләшкән тамашалар күрсәтү аша балаларда артистлык сәләтен үстерү.

**Программаның актуальлеге:**

Белем бирү стандартларының яңалыгы-белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе–коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы.Ягъни,баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп,әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү.Бу таләп-түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә.

Баланы төрле яклап үстерү өчен,иң беренче чиратта,аның нәрсәгә сәләтле булуын ачыклау да җитә.Бу очракта күпләгән санда түгәрәкләргә йөрүдән тыш,аңа туры килә торган берсен сайлап алырга мөмкин.

Балаларны берләштерүдә,зурлар белән аралашуга өйрәтүдә,сөйләм телен үстерүдә,җәмгыятьтә үз-үзен тота белеп,актив һәм сәләтлекеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

Бу-бүгенге көндә бик актуаль.Театр-балаларга якын булган сәнгать төре.Шуның нәтиҗәсендә заманча педагогика һәм психология алдында торган проблемалар хәл ителә:

-балаларга белем һәм тәрбия бирү,

-эстетик зәвык үсеше,

-әхлакый тәрбия,

-коммуникатив сыйфатлар үсеше,

-аралашу культурасын тәрбияләү,

-ихтыяр көче тәрбияләү,хәтерне үстерү(диалог,моголог) һ.б.

Баланың бөтен тормышы-уен.Уенда бала тирә-юнь турында,җәмгыятьнең законнары,кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый,ә бу дөньяда яшәргә,үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә.
Ә бу баланың игътибарлы,яхшы хәтерле,дөрес,матур,әйбәт сөйләшә белүен таләп итә.

Сәхнәләштерү уеннарында катнашып,балалар образлар,төсләр,авазлар аша тирә-юнь белән танышалар,ә сораулар балаларны уйларга,анализларга,
йомгаклау ясарга мәҗбүр итә.Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда,һәр бала үзенең кичерешләрен,тойгыларын,теләкләрен,карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел,ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк.Еш кына без иң белемле,сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен,чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез.Бу проблемалар булмасын өчен,балалар бакчасында театр кую бик зур булышлык күрсәтә.Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар.Спектакльләрдә катнашып,балалар тирә-юнь
белән,төсләр,авазлар белән танышалар,ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга,уйланырга,нәтиҗәләр ясарга өйрәтә.Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында сизелмичә баланың сүз байлыгы арта,чиста,
дөрес,аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә.

Театр – балаларга якын булган сәнгатьнең бер төре. Шуның нәтиҗәсендә заманча педагогика һәм психология алдында торган актуаль проблемалар хәл ителә:

-балаларга белем һәм тәрбия бирү.
-эстетик зәвык үсеше.
-әхлакый тәрбия.
-коммуникатив сыйфатлар үсеше.
-аралашу культурасы тәрбияләү.
-ихтыяр көче тәрбияләү, хәтерне, күзаллауны, фантазияне, сөйләмне үстерү (диалог, монолог)
-уңай эмоциональ кәеф булдыру, киеренкелекне йомшарту, конфликатлы ситуацияләрне уен аша чишү.

Театраль эшчәнлекнең тәрбияви мөмкинлекләре бик зур, аның тематикасы баланың күп кырлы кызыксынуларын һәм теләкләрен кәнәгатьләндерә ала. Бала әйләнә - тирә һәм аның күптөрлелеге белән таныша, үзен әйләндереп алган мохиткә җайлаша, ә тәрбиябенең төгәл куелган сораулары балага уйланырга, анализ ясарга, дөрес нәтиҗә чыгарырга ярдәм итә.
Нинди яшьтә булуга карамастан, кеше әкиятләрдә ниндидер серле, дулкынландырган хәзинә ачарга мөмкин. Бала вакытта әкиятләр тыңлап, кеше үзе дә уйламыйча тормыш турында мәгълүмат туплый, шуңа күрә “Әкият безне нәрсәгә өйрәтә? дигән сорау аша "әкият дәресләрен" танып белү кечкенәдән башланырга тиеш. Һәр баланың күңелендә ирекле театральләшкән уен теләге яшерелгән. Нәкъ менә шул, баланың уйлавын активлаштыра, хәтерен һәм кабул итүен, күзаллавын, фантазияне үстерә,

сөйләм телен камилләштерә. Театраль эшчәнлекнең тәрбияви мөмкинлекләре күпъяклы: аның тематикасы чикле түгел, шуңа күрә ул баланың кызыксынуларын һәм теләкләрен кәнәгатьләндерә ала. Театраль эшчәнлектә катнашып, бала әйләнә – тирә һәм аның төрлелеге белән - образлар, төсләр, авазлар, музыка аша таныша, тәрбияченең дөрес куелган сораулары, балага уйларга, анализ ясарга, нәтиҗә чыгарырга ярдәм итә. Нәкъ менә театральләшкән эшчәнлек сәнгатьле сөйләм, инлеллектуаль һәм әдәби – эстетик тәрбиягә караган тәрбияви бурычларның күбесен чишәргә ярдәм итә. Театральләшкән эшчәнлек беренче чиратта – ул импровизация, предмет һәм авазларны җанландыру. Ул башка төрле эшчәнлекләр белән дә тыгыз бәйләнгән – җыр, көйгә хәрәкәтләнү, тыңлау. Алар барысы даербөтен эшчәнлек булып торалар.

**Театраль эшчәнлек** – бала иҗатының иң киң таралган төре. Образга кереп, бала төрле рольләрне уйный, аннан үзенә эмоциональ ләззәт ала. Театраль эшчәнлек шөгыльләре баланың кызыксынуларын, сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен үстерә, бала яңа белемнәр алырга ашкына, үз максатына ирешергә ярдәм итә.

**Программада катнашучылар**: Мәктәпкәчә яшьтәге балалар 5-6 яшь,театр түгәрәге җитәкчесе, ата-аналар.

**Программаны тормышка ашыру вакыты:** 9 ай

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

-балаланың милли культура,театр,артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе;
-балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү,сүзлек запасы артуы;
-әкиятләр аша балалар кешеләргә хас уңай сыйфатлар белән очраша (миһырбанлык,шәфкатьлелек һ.б),әхлак тәрбиясенә өйрәнү;
-өстәл театры,магнитлы театр сәхнәләштерә алуы;
-сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу;
-сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү;
-үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу;
-гаилә белән балалар бакчасы арасында җылы элемтә була җылы мөнәсәбәт урнаша.
- балаларның әкиятләр белән кызыксынулары үсүе, коллектив эшендә катнашу теләге, матурлыкка омтылыш, сәнгать кешеләренә хөрмәт , театраль эшчәнлек аша иҗади шәхес тәрбияләнүе, сөйләм телләре баю.
-эстетик, иҗади зәвыклары үсү.
- театр сәнгатенә карата мәхәббәт, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяну.
- балаларның театр һәм театр төрләре турында белемнәре барлыкка килү.

- әкият геройларының хис – тойгыларын, халәт – кичерешләрен дөрес тасвирлый белергә өйрәнү.
- төрле театральләшкән тамашалар күрсәткәндә балаларда артистлык сәләтләре үсү.
- рольләрне тырышып башкару, атрибутларын һәм җиһазларын эш беткәч урынына алып кую, сакчыллык күнекмәләре формалашу.
-мәктәптә укырга өйрәнүгә әзерлек формалашу, сенсор һәм моторик күнекмәләре киңәю.

**Программаның билгеләнеше:**

5-6 яшьлек балалар белән татарча театр түгәрәге айга 8 тапкыр,атнага 2 мәртәбә үткәрелә.Балаларның сәхнәләштерү эшчәнлеге көннең икенче яртысында уза.Түгәрәкне үткәрү вакыты: зурлар төркеме- 25- 30минут

Түбәндәге принципларга таянып эшләү мәҗбүри:
-педагогның әзерлеге;
-педагогик процессны оештыруның бөтен формаларын куллану;
-барлык баланың максималь актив катнашуы;
-бай эчтәлекле,темаларның һәм методик алымнарның төрлелеге;
-иптәшләре һәм педагоглар белән хезмәттәшлек.
Программа материалын өйрәнү 36 сәгатькә исәпләнә.
Сәхнәләштерү эшчәнлеге:

- курчак театры карау һәм алар буенча әңгәмә оештыру;
- уен- драматизацияләр;
- сәнгатьле итеп сөйләү күнегүләре;
- этика буенча аерым күнегүләрне үз эченә ала.

Ә менә тәрбияче үзе сәнгатьле итеп сөйләү генә түгел, күрә, ишетә белергә, актерлык, режиссерлык осталыгына да әзер булырга тиеш. Тик ул үзенең актерлык осталыгы белән оялчан баланың уйнау теләген бетереп, караучыга әйләндерергә тиеш түгел. Балалар ялгышудан куркырга, гел караучы гына яки гел катнашучы гына булырга тиеш түгел.
Рольләргә бүлгәндә төрле алымнар кулланыла:

- баланың теләге буенча роль сайлау;
- төп рольләргә оялчан балаларны билгеләү;
- карточкалар буенча рольләргә бүлү;
- парлап уйнау.

Монда ике проблема килеп чыгарга мөмкин:

- һәр балага рольләр житмәсә нишләргә;
- тискәре рольләрне кем уйнар

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишеп була. Ә икенчесен аңлатырга: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та, һәр бала тискәре рольне дә, уңай рольне дә уйный белергә тиеш.

**Эчтәлекне тәэмин итү принциплары:**

Үзләштергән белем һәм күнекмәләрнең балага рус әдәбиятын һәм башка милләтләр әдәбиятын үзләштергәндә дә ярдәм итә ала торган булу зарурлыгы.

- Аңлаешлылык (доступность) принцибы.

Баланың нигез белемнәренә таянып, проблемалар, каршылыклар аша җиңеп чыгарлык, көче җитәрлек әсәрләрнең кулланышка куелуы.
Белем бирүдә фундаментальлек принцибы

- Мотивлылык принцибы.

Балаларның тормыш тәҗрибәләре, кызыксыну даирәләре белән тәңгәл килерлек, гыйбрәт яисә үрнәк алып тормыш тәҗрибәләрен баетырлык әсәрләрнең генә кулланышка куелуы. Танып-белү процессының психологик иркенлек шартларында оештырылу зарурлыгы.

- Күп мәдәни нигезлелек (поликультуралылык) принцибы.
  Гомумкешелек кыйммәтләренә, сәнгать әсәре тудыра алган авторга (төрле милләт халкына да) ихтирам һәм кызыксыну хисләре уяну өчен; программа таләп иткән төп төшенчәләрнең татар һәм рус телләрендә үзләштерелүе өчен җирлек тудырылу.
- Системалы эшчәнлек ( системно- деятельностный подход) принцибы.
  Программа таләп иткән эчтәлекне гадидән катлаулыга принцибы нигезендә бербөтен буларак үзләштерелүе тәэмин ителү.

**Программаны тормышка ашырганда, балалар белән эштә, түбәндәге формалар кулланыла:**

-Әкиятләрне уку һәм күмәк анализ ясау.
-әкият өлешләрен уйнау.
-компьютер кулланып, әкиятләр, такмаклар, шигырьләр тыңлау.
-Режиссер уены (төзелеш һәм дидактик материал белән).
-Әкиятләрдәге вакыйгаларны комментарий бирү аша рәсемдә чагылдыру яки буяу.
-Сүзле, өстәл һәм хәрәкәтле уеннар.
-Пантомимик этюдлар һәм күнегүләр.
-сулыш гимнастикасы.
-Артикуляцион гимнастика.
-Сүзле бармак уеннары.
-Тизәйткечләр өйрәнү.

**Балалар белән эшләү кагыйдәләре:**

-Балаларның теләге буенча роль сайлау;
-Өйрәнгән әдәби әсәрне бергәләп уйнарга теләк уяту;
-Һәр баланың уйнаган ролен, яулаган уңышларын билгеләү;
-театр эшчәнлеген төрләндереп тору, яңа бурычлар кую, еш репетицияләрне булдырмау;

**Балаларның көтелгән белеме :**

-Мөстәкыйль рәвештә әкият, шигырь, җыр сайлый ала;
-Төрле әкият героен сурәтли белергә өйрәнә;
-Тизәйткечне, җөмләләрне  төрле интонация, төрле темпта әйтә ала;
-Әкиятләр буенча этюдлар уйлап таба;
-Гади диалог төзи ала;
-Рольләрне һәм йөкләмәләрне үзара бүлә белә.

**Театраль  эшчәнлек белән шөгыльләнеп балаларда:**

-Үз – үзләрендә ышаныч.
-коллективта уйный алу сәләте барлыкка

**Күрсәтмәлелек чаралары:**

-театраль ширма,битлекләр,костюмнар, йомшак уенчыклар, иллюстрацияләр,рәсемнәр,өстәл арты уеннары,слайдлар,мультфильм җыентыклары,музыкаль бизәлеш өчен дисклар,агачлар,өй ширмасы ,төрле зурлыктагы кәрзиннәр,кечкенә чиләкләр,көянтә,өстәл,урындыклар, кечкенә караватчигелгән сөлгеләр,ашъяулык,агач төпләре,бүрәнә,эскәмья, чәчәкләр,шарлар,койма,мич,ноутбук,проектор,экран.

**Эш формалары:**

-ата-аналарның фикерләрен өйрәнү;
-экскурсияләр;
-кечкенәләр каршында чыгыш ясау;
-татар халык авыз иҗаты,матур әдәбият үрнәкләре белән танышу;
-тел гимнастикасы,артикуляцион күнегүләр ясау;
-очрашулар;
-әңгәмә,фикер алышулар;
-рәсемнәр,иллюстрацияләр,мультфильмнар карау;
-җырлы-биюле,сүзле,өстәл арты уеннары;
-ата-аналар өчен йомгаклау күңел ачу кичәсе.

# Программаның тематик планы

| № | Ай исеме | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1 | Сентябрь | **“Театр яктылыкка,нурга илтә”** | 8 сәгать |
| | | 1 атна.”Без –яшь артистлар”. | |
| | | 2 атна.”Бармак уеннары “ көне. | |
| | | 3 атна “Нәрсә ул театр?<br>Театр турында әңгәмә. | |
| | | 4 атна.”Театрда нинди һөнәр ияләре эшли?”<br>Дөрес сулыш алу һәм артикуляциягә уен-күнегүләр. | |
| 2 | Октябрь | 1атна. “Балалар бакчасында театраль эшчәнлек” .Әңгәмә.<br>“Театр илендә “ | |
| | | 2 атна.Җырлы –биюле уеннар.<br>“Башмакчы “ уенын өйрәнү. | |
| | | 3 атна. Балалар бакчасында Әлмәт “Алина” курчак театры белән танышу.Курчак театры карау. | |
| | | 4 атна.Тавышларның төрле<br><br>төсмерләре. | |
| 3 | Ноябрь | **“Сөмбеләгә-кунакка!”** | |
| | | 1 атна.“Аюның туган көне”әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек. | 8 сәгать |
| | | 2 атна.Рольләргә бүлү,өйрәнү.<br>Репетицияләр. | |
| | | 3 атна.Әкият өчен “Дуслык” җырын өйрәнү.<br>Репетицияләр. | |
| | | 4 атна.Ата-аналар өчен күңел ачу кичәсе.”Сөмбеләгә-кунакка!” | |
| 3 | Декабрь | **“Борын-борын заманда”** | 8 сәгать |
| | | 1 атна.”Татар халык уеннары көне”.<br>“Кәрия-Зәкәрия”<br>”Интонация:икеләнәбез,сокланабыз, аптырыйбыз,куанабыз!” | |
| | | 2 атна.”Әкиятләр көне”.<br>Тавышның төрле төсмерләре. | . |

| | | | |
|---|---|---|---|
